**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**14-РС** **2019 елның 3 апреленнән**

# РЕШЕНИЕ

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау тәртибе һәм аңа үзгәрешләр кертү турында Кагыйдәне раслау турында**

2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 маддәсенә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июленнән №45-ЗРТ “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы законына, Татарстан Республикасының 2010 елның 25 декабреннән №98-ЗРТ “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында”гы законына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына ярашлы төстә, Лаеш муниципаль район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау тәртибе һәм аңа үзгәрешләр кертү турындагы кушып бирелүче Кагыйдәне расларга.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү буенча Комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - муниципаль район Советы рәисе вазифаларын башкаручы** **Т.П.Бурганова**